**ТАТАРСТАН**

**РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧАЛМАНАРАТ**

**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**423752, Чалманарат авылы, Үзәк ур., 2 йорт**

**СОВЕТ ЧАЛМАНАРАТСКОГО СЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**423752, село Чалманарат, ул.Центральная, 2**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.03.2021 ел № 3

**Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советының 17 марта 2016ел, №7 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чалманарат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы , «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Чалманарат авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чалманарат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында, Чалманарат авыл җирлегенең 17.03.2016ел №7 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 пунктның «в» пунктчасында «оешмалар» сүзләреннән соң, «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә»;

1.2. 13 пунктта «оешмалар» сүзләреннән соң, «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Чалманарат авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманаратвыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Чалманарат авыл җирлеге Советы Рәисе К.С.Ахметов